СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 17 декабре** Бишнә ав. **№ 18**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт хакы күләмен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 28.09.2020 №7 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Советның 26.09.2022 №97, 29.12.2022 №117, 03.06.2024 №186, 05.12.2024 №206, 29.04.2025 №224 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәтенә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 28.09.2020 елның 7 номерлы карарына (Советның 26.09.2022 № 97, 29.12.2022 №117, 03.06.2024 №186, 05.12.2024 №206, 29.04.2025 №224 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1). 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «21091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 27208 (егерме җиде мең ике йөз сигез) сум күләмендә» сүзләрен «23 201 (егерме өч мең ике йөз бер) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 29930 (егерме тугыз мең тугыз йөз утыз) сум күләмендә» сүзләре белән алмаштырырга;

2). 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «21091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә» сүзләрен «23 201 (егерме өч мең ике йөз бер) сум күләмендә сүзләре белән алмаштырырга»;

3) 3 пунктта «2025 елның елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга»;

4) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бишнә авыл җирлеге Советының
2025 елнын 17 декабрендаге №18
карарына Кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ

| Муниципаль хезмәт вазыйфаларының атамалары | Вазифаи хезмәт хакы айлык күләме, сум |
|---|---|
| Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) | 22 515 |
| Әйдәп баручы белгеч | 18 791 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**